**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПЕЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 с. Пелево,
ул. Советская , д. 9
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПӘРӘҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422610 Пәрәү,
Совет урамы, 9 нче йорт,
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

---

**2023 елның 8 ноябре** **11 номер**

# КАРАР

**«Пәрәү авыл җирлеге Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 20 июлендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Пәрәү авыл җирлеге Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 20 июлендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарга, кушымта нигезендә,үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Пәрәү авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Пәрәү авыл җирлеге
Советы рәисе:** **Ф.Ф. Тимергалиев**

*Татарстан Республикасы*
*Лаеш муниципаль районының*
*Пәрәү авыл җирлеге Башкарма комитетының*
*2023 елның «08» ноябрендәге 11 номерлы*
*карарына кушымта*

**«Пәрәү авыл җирлеге Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 20 июлендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"**

**3.3.2.1 пунктның 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:

-Формалаштырылган гаризаны форматлы-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче һәр кырны электрон рәвештәге кырны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон сорау формасы кыры ачыкланганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр аша турыдан туры электрон формасында хәбәр ителә.